Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы
Әлмәт авыл Советы

КАРАРЫ

6 май 2019 ел № 114

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт авыл Советының «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт авыл җирлеге территориясендә физик затларның милкенә салым турында» 2014 елның 19 ноябрендәге № 117 карарына үзгәрешләр кертү турында»

Россия Федерациясе Салым кодексының 32 бүлеге, 2018 елның 3 августындагы «Россия Федерациясе Салым кодексының 52 статьясы беренче һәм икенче өлешенә үзгәрешләр кертү турында» №334-ФЗ Федераль закон нигезендә

Әлмәт авыл Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт авыл Советының 2014 елның 19 ноябрендәге № 117 «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт авыл җирлеге территориясендә физик затларның милкенә салым турында» карарына (Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт авыл Советының 2015 елның 05 маендагы № 136, 2015 елның 29 октябрендәге № 6, 2018 елның 20 августындагы № 90 карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. карарның 2 пунктында:

1.1.1. 2 нче пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2) 0,2 процент:

фатир, фатир өлеше;

бүлмәгә карата;»;

1.1.2. 3 нче пунктчаның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3) торак йортлар, торак йортларның өлешенә;»;

1.2. 2 нче пунктның 1 пунктчасының икенче абзацын «шул исәптән салым салу объектларында әлеге пунктның 4 пунктчасында күрсәтелгән» сүзләре белән тулыландырырга;

1.3. түбәндәге эчтәлекле 3 нче пунктны өстәргә:

«3. Физик затлар милкенә салым түләүдән азат итү:

3.1. 18 яшькә кадәрге өч һәм аннан да күбрәк балалары булган гражданнар;

3.2. әлеге пунктның 3.1 пунктчасында күрсәтелгән гражданнарның балалары;

3.3. тулы дәүләт тәэмин ителүендә булган балалардан тыш, инвалид балаларның ата-аналары (уллыкка алучылар, опекуннар, попечительләр);

Салым ташламасы салым салу объектларының түбәндәге төрләренә карата бирелә:

1) фатир, фатирның бер өлеше яки бүлмә;

2) торак йорт яки торак йортның бер өлеше.

Салым ташламасы гаиләгә туры килә торган салым салуның салым түләүченең теләге буенча бер объектына карата бирелә.

Салым ташламасы җирлек территориясендә даими яшәүче салым

түләүчеләргә, салым түләүче милкендә булган һәм эшмәкәрлек эшчәнлегендә файдаланылмый торган салым салу объектына карата бирелә.

Салым ташламаларына хокукы булган физик затлар салым органына салым ташламалары бирү турында гаризаны үз теләге белән бирәләр, шулай ук салым түләүченең салым ташламасына хокукын раслаучы документларны тапшырырга хокуклы.

Салым ташламасына хокукны раслаучы документлар булып түбәндәгеләр тора: әлеге салым буенча салым түләүче дип танылган физик затның шәхесен таныклаучы документ, шулай ук аның исеменә бирелгән күп балалы гаилә таныклыгы, яисә өч һәм аннан күбрәк бала туу турында таныклык.

Салым ташламасы бирелә торган салым салуның сайланган объектлары турында хәбәр хаты салым түләүче тарафыннан елның 1 ноябренә кадәр салым чоры булып торган салым органына тапшырыла, аннан башлап күрсәтелгән объектларга карата салым ташламасы кулланыла».

1.4. карарның 3, 4, 5 пунктларын 4, 5, 6 пунктлар дип санарга.

2. Әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырырга, «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматлар рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Әлмәт авылы, Яшьләр бистәсе, Школьная урамы, 3 нче йорт; Дербедень авылы, Совет урамы, 32 а нче йорт; Бота урманчылыгы торак пунктлар территориясендә урнашкан махсус мәгълүмати стендларда халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карарның 1 нче пунктының 1.1 һәм 1.2 пунктчаларының гамәлдә булуы, 2017 елның 1 гыйнвареннән физик затлар милкенә салым исәпләүгә бәйле хокукый мөнәсәбәтләргә кагыла, карарның 1 пункты 1.3 пунктчасы рәсми басылып чыккан көненнән соң бер айдан да иртәрәк үз көченә керми һәм 2018 елның 1 гыйнвареннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә карата үз көчен бирә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Әлмәт авыл җирлеге башлыгына йөкләргә.

Әлмәт авыл
җирлеге башлыгы А.А. Веретенцев